СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Наласа авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**“18” ноябрь 2019 ел** **№ 98**

**Наласа авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 44 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге Уставы нигезендә Наласа авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Наласа авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 44 номерлы «Җир салымы турында» карарына (Наласа авыл җирлеге Советының 2019 елның 21 августындагы 89 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 3.1.1 пунктындагы беренче абзацында «автомобиль юллары» сүзләреннән соң «, әлеге карарның 2 пунктындагы 2.1 пунктчасында күрсәтелгәннәрдән тыш, " сүзләрен өстәргә»;

2) 4 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасының гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән бер ай үткәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Наласа авыл җирлеге башлыгы И.Р. Шакирова